РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«26» март 2025ел

№ 54

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27 декабрендәге 177 номерлы «2025-2027 елларга Теләче муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27 декабрендәге 177 номерлы «2025-2027 елларга Теләче муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына, Программага кушымтаны түбәндәге тәртиптә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 27 декабрендәге
177 номерлы карарына
(«26» 03 2025 № 54
карар редакциясендә)кушымта

**Муниципаль Программа**
**«2025-2027 елларга Теләче муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгын үстерү»**

**Муниципаль Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2025-2027 елларга Теләче муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Программаның заказчысы-координаторы | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты | Урам-юл челтәрен, автомобиль юлларын һәм җирле әһәмияттәге юл корылмаларын камилләштерү, аларның транспорт-эксплуатация күрсәткечләрен Теләче муниципаль районының һәм җирлекләрнең социаль - икътисади үсеш өстенлекләрен исәпкә алып, автоюллардан файдаланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле дәрәҗәдә тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | - юл хуҗалыгын ремонтлау һәм карап тоту эшләре күләмен арттыру хисабына гамәлдәге урам-юл челтәренең һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының техник торышын яхшырту;<br>- муниципаль берәмлекләрнең юл хуҗалыгы белән идарә итү системасын камилләштерү;<br>- Теләче районы муниципаль берәмлекләренең юл хуҗалыгы өлкәсенә өстәмә инвестицияләр җәлеп итү |
| Программаны башкаручылар | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре | Норматив таләпләргә туры килми торган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары өлеше.<br>Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары өлеше, аларга карата ремонт ясалган.<br>Юл хуҗалыгына муниципаль берәмлекләр бюджетларының һәм бюджеттан тыш чыганакларның чыгымнары күләме.<br>Муниципаль берәмлекләр бюджетлары чыгымнарының гомуми күләмендә юл хуҗалыгына чыгымнар өлеше |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2025-2027 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2025-2027 елларда Программаны финанслауга Теләче муниципаль районы (муниципаль юл фонды) бюджеты акчалары исәбеннән түбәндәгеләр каралган:<br>2025 - 27711,83 мең сум;<br>2026 - 26700,20 мең сум;<br>2027 - 27530,60 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фараз характерына ия |

| | |
|---|---|
| | һәм чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Теләче муниципаль район Советы карары нигезендә тәгаенләнәчәк |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Программаны тормышка ашыру ярдәм итәчәк:<br>- йөрү уңайлыгын һәм җайлылыгын арттыруга;<br>- якын-тирә территорияләрнең гомуми икътисади үсешен стимуллаштыруга;<br>- транспорт үтемлелеген арттыруга;<br>- юл - транспорт һәлакәтләре санын киметүгә |

## 1. Кереш

«2025-2027 елларга Теләче муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгын үстерү» муниципаль Программасы (алга таба - Программа) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан эшләнде.

Программада гамәлдәге автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын реконструкцияләү, ремонтлау һәм транспорт-эксплуатацияләү торышын яхшырту нәтиҗәсендә 2025-2027 елларга Теләче районы торак пунктларында жирле әһәмияттәге автомобиль юллары челтәрен һәм урам-юл челтәрен камилләштерү һәм үстерү нигезләнә.

Әлеге программаны тормышка ашыру икътисадны үстерүгә, халыкның тормыш шартларын яхшыртуга һәм районның торак пунктлары арасында ышанычлы элемтәләрне тәэмин итүгә, шулай ук муниципаль район һәм авыл җирлекләренең Хезмәт, табигый, житештерү һәм инвестиция ресурсларыннан файдалануның активлыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итәчәк.

Программада 2025-2027 елларга ремонтлау һәм реконструкцияләү өчен планлаштырылган автомобиль юллары, урамнар һәм юл корылмалары Исемлеге, юлларны һәм корылмаларны капиталь ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту буенча эшләр күләме, Теләче муниципаль юл фондының юл эшләрен финанс белән тәэмин итүгә ихтыяҗы билгеләнгән.

## 2. Теләче муниципаль районының юл хуҗалыгы торышына анализ һәм үсеш проблемалары

Теләче муниципаль районында 53 торак пункт бар, шул исәптән административ үзәк – Теләче авылы. Районның барлык торак пунктлары региональ һәм муниципаль әһәмияттәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары белән бер-берсенә бәйле, аларның гомуми озынлыгы 394 км тәшкил итә. Күрсәтелгән юллар буенча 12 мәктәп автобус маршруты уза. Район буенча даими автобус маршрутлары юк.

Муниципаль җирлекләр милкендәге авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан муниципаль юллар, урам-юл челтәре һәм юл инфраструктурасы объектлары жирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларга керә. Җирле әһәмияттәге юллар исемлеге Теләче муниципаль районы Башкарма

комитетының 2012 елның 12 декабрендәге 969 номерлы карары белән расланган (Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 октябрендәге 273 номерлы карары редакциясендә).

## 3. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты: урам-юл челтәрен, автомобиль юлларын һәм җирле әһәмияттәге юл корылмаларын камилләштерү, автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту эшләрен вакытында һәм сыйфатлы башкару нигезендә автомобиль юлларыннан файдаланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле булган дәрәҗәдә транспорт-эксплуатация күрсәткечләрен тәэмин итү.

Программаның бурычы:

- юл хуҗалыгын ремонтлау һәм карап тоту эшләре күләмен арттыру хисабына гамәлдәге урам-юл челтәренең һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының техник торышын яхшырту;
- муниципаль берәмлекләрнең юл хуҗалыгы белән идарә итү системасын камилләштерү;
- Теләче муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең юл хуҗалыгы өлкәсенә өстәмә инвестицияләр җәлеп итү.

2025 елга Теләче муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре Программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге

| № т/б | Объектның исеме | Егәрлеге (км, п.м., кв.м.) | | | Гамәлдәге бәяләрдә капитал салулар (мең сумнарда) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | км | п. м. | кв. м. | |
| 1. | Теләче ав. Овражная, Спротивная ур., "Теләче ав. керү" а/б өслек урнаштыру | | | 1709,4 | 19315,00 |
| 2. | Теләче ав. Дальняя ур. а/б өслек урнаштыру | | | 1180 | 6446,40 |
| | Барлыгы: | | | | 25758,40 |
| | ЮХК чаралары | | | | |
| 1. | Теләче авылында Ленин ур., 1 йорт алып Школьная урамына кадәр юл өлешен яктырту | | | 435 | 1953,43 |
| | Барлыгы: | | | | 1953,43 |
| | 2025 елга МЮФ планы буенча барлыгы | | | | 27711,83 |

2026 елга Теләче муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре Программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге

| № т/б | Объектның исеме | Егәрлеге (км, п.м., кв.м.) | | | Гамәлдәге бәяләрдә капитал кертемнәр (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | км | п. м. | кв. м. | |
| 1. | Теләче авылы урамнарын түшәү ремонты | | | 2514 | 14830,20 |
| 2. | Теләче ав. тротуарлар | | | 1740 | 5370,00 |
| 3. | Мәгариф, мәдәният объекты территориясе | | | 870 | 6500,00 |
| | 2026 елга МЮФ планы буенча барлыгы | | | | 26700,20 |

2027 елга Теләче муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге

| № т/б | Объектның исеме | Егәрлеге (км, п.м., кв.м.) | | | Гамәлдәге бәяләрдә капитал кертемнәр (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | км | п. м. | кв. м. | |
| 1. | Теләче авылы урамнарын түшәү ремонты | | | 2175 | 14830,60 |
| 2. | Теләче ав. тротуарлар | | | 1810 | 5200,00 |
| 3. | Мәгариф, мәдәният объекты территориясе | | | 1305 | 7500,00 |
| | 2027 елга МЮФ планы буенча барлыгы | | | | 27530,60 |

## 4. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаның үтәлешен планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм гомуми контрольне программаның координаторы - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра, ул ел саен Программаның максатчан күрсәткечләрен һәм чараларына чыгымнарны, аны тормышка ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын тәгаенли.

Программаны гамәлгә ашыру ел саен план нигезендә үтәлә, анда, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеге урын ала.

Чараларны финанслау аларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы һәм Программаны үтәүче учреждениеләр, оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар программаның координатор - муниципаль заказчыга квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 10 көненә кадәр, чараларның үтәлеше һәм башкаручыларга бүлеп бирелә торган чараларның үсү нәтиҗәсе һәм тулаем хисап елы өчен үзләштерелгән акчалар турында мәгълүмат бирәләр.

Программаны гамәлгә ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап (алга таба - еллык хисап) муниципаль заказчы - Программа координаторы, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр бергәләп, Теләче муниципаль районы советына, Теләче муниципаль районы Башлыгына тапшыра.

Еллык хисап үз эченә ала:

- хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;

- билгеләнгән срокларда башкарылган һәм үтәлмәгән (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеге;

- программаны тормышка ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;

- бюджет ассигнованиеләреннән һәм чараларны үтәү өчен башка чыганаклардан файдалану турында белешмәләр;

- программага җаваплы башкаручы тарафыннан кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат;

- башка мәгълүмат.

Программага үзгәрешләр кертү Программа чараларын җаваплы башкаручы тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры китереп гамәлгә ашырыла.

Программа чараларының үтәлешен һәм финанс чараларыннан нәтиҗәле файдалануны Теләче муниципаль районы Советы утырышларында, программаны башкаручы җитәкчеләрне тыңлап, карау планлаштырыла.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз-үземә калдырам.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин